**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ**
**ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**

422370 г.Тетюши, ул.Малкина, 39

422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур, 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru
ОКПО 78702097, ОГРН 1061672000037, ИНН/КПП 1638004978/163801001

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**27 .11. 2023** **№ 40-5**

**Тәтеш муниципаль районы Советының «Тәтеш муниципаль районында муниципаль торак контроле турында Нигезләмәне раслау турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 14-4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (Тәтеш муниципаль районы Советының 28.02.2022 ел, № 19-2, 05.06.2023 ел, № 33-3 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән)**

Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясына, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 31.07.2020 № 248-ФЗ Федераль Законына, Тәтеш муниципаль районы Уставына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Тәтеш муниципаль районы Советының 29.11.2021 ел, № 14-4 карары белән расланган Тәтеш муниципаль районында муниципаль торак контроле турында нигезләмәнең 1 нче кушымтасына үзгәрешләр кертергә, кушымта буенча аның яңа редакциясен бәян итәргә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча урнаштырырга: http://tetushi.tatarstan.ru/.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Тәтеш муниципаль районы Советының Җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Башлыгы** **Р.Х. Сафиуллов**

Кушымта

**Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан Тәтеш муниципаль районында муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда планнан тыш тикшерүләр үткәрү кирәклеген билгеләү өчен кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары**

1. Муниципаль торак фондының торак биналары булган күпфатирлы йортта, көн тәртибендәге шундый ук мәсьәләләр буенча карарлар булган, милекчеләрнең гомуми җыелышының ике һәм аннан да күбрәк беркетмәсен өч ай рәттән муниципаль торак контроле органына кертү.

2. Дәүләт торак күзәтчелеге органына, муниципаль торак контроле органына гражданнардан (мөрәҗәгать иткән гражданның шәхесен билгеләргә мөмкинлек бирә торган ысул белән килгән) яки бина хуҗалары булган оешмалардан алдагы календарь елның шул ук чоры белән чагыштырганда, вакыт берәмлегендә (ай, квартал) мөрәҗәгатьләр санының өч тапкыр һәм аннан да күбрәк артуы күпфатирлы йортта яшәүче гражданнар, күпфатирлы йорттагы биналарны кулланучылар, дәүләт хакимияте органнарыннан алынган мәгълүмат, җирле үзидарә органнары, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясының 1 өлешендә билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне контрольдә тотучы затлар тарафыннан бозу фактлары турында дәүләт мәгълүмат системаларыннан.

3. Россия Федерациясе Торак Кодексының 165 статьясының 5 өлеше нигезендә билгеләнгән тәртипкә, формаларга, срокларга һәм вакытлычалыкка ярашлы рәвештә торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылырга тиешле мәгълүматның өч һәм аннан да күбрәк ай дәвамында актуальләшмәве.

4. Бердәм диспетчерлык хезмәте мәгълүматларына караганда, контрольдә тотылган зат идарәсендә күп фатирлы йортта гомуми милектәге җитешсезлекләрне бетерү буенча эшләр башкару өчен атнага биштән артык ремонт бригадасы чакырыла.

5. Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү документларында күпфатирлы йорт милекчеләренең гомуми мөлкәтен файдаланганда һәм тотканда кулланыла торган коммуналь ресурслар өчен түләү күләмен алдагы шундый ук исәп-хисап чоры белән чагыштырганда 50% тан артык арттыру турында белешмәләрне ачыклау.